| БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ |
| --- | --- |

| **РЕШЕНИЕ** | **КАРАР** |
| --- | --- |
| 18 гыйнвар 2022 ел | № 107 |

**«Авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү вәкаләтен тапшыру турында» 2021 елның 8 ноябрендәге 84 номерлы Татартан Республикасы Балтач район Советы карарының үз көчен югалтуын тану хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район Советы карар бирде:

1. «Авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү вәкаләтен тапшыру турында» 2021 елның 8 ноябрендәге 84 номерлы Татрстан Республиасы Балтач район Советының карары үз көчен югалткан дип таныргa.
2. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетына Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы авыл җирлекләре башкарма комитетлары белән авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү буенча вәкаләтне төшереп калдыру турында килешүләр төзергә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты Җитәкчесенә йөкләргә.

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач район Советы рәисе — Р.Р.Нотфуллин